# Мәдрәсәле авылның мәртәбәле мәктәбе



**Фәргать НИГЪМӘТҖАНОВ,**
*Саба районының Ш.Зиннуров исемендәге Сатыш урта мәктәбе директоры*



**Мәфрүзә ХӘСӘНОВА,**
*Саба районының Ш.Зиннуров исемендәге Сатыш урта мәктәбе директорының укыту-тәрбия эшләре буенча урынбасары*

## Чишмә башыбыз мәдрәсәдән башлана

«Татарстанның иң яхшы 100 авыл мәктәбе» исемлегенә берничә тапкыр кергәнебез бар иде инде. Ә менә узган уку елы нәтиҗәләре буенча республикабызның иң яхшы 20 авыл мәктәбе арасында булу бигрәк тә сөенечле, әлбәттә. Һәм бу очраклы гына түгел, чөнки авылыбыздагы гыйлем чишмәсе XVIII гасырда ук иң мәртәбәле уку йортларыннан саналган Сатыш мәдрәсәсеннән башлангыч ала. Күренекле язучыбыз Мөхәммәт ага Мәһдиев үзенең «Без кемнәр?» дигән мәкаләсендә: «Сатыш мәдрәсәсе ... заманында Арча, Тәкәнеш, Кукмара, Мамадыш, Балык Бистәсе яклары өчен шәм-лампа ролен үтәгән. Монда шагыйрь Миргазиз Укмаси, язучы һәм әдәбият белгече Мөхәммәт Гали, шулай ук минем газиз әтием – булачак имам-хатыйп укыган. Болар әле мин белгәннәре генә. Сатыш мәдрәсендә белем алган шәкертләр камил рәвештә гарәп телен белеп чыккан», – дип язган. Безнең Сатыш мәдрәсәсе Габделбари Батталның «Казан төркиләре»; Ирек Һадиев, Раиф Мәрдановның «Саба төбәгенең эпиграфик истәлекләре»; Радик Салихов, Рамил Хәйретдиновның «Татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре» дигән китап һәм мәкаләләрендә дә шактый тулы яктыртылган. Шунысын да искәртик: хәзерге вакытта авылыбыздагы әлеге мәдрәсә бинасында реставрация эшләре бара. Киләчәктә анда бөтен татар дөньясындагы мәдрәсәләрнең тарихын яктырткан виртуаль музей ачылачак.

## Предметларны татарча укытып та, БДИ буенча югары күрсәткечләргә ирешергә мөмкин

Әлбәттә, Татарстан күләмендә иң яхшы 20 авыл мәктәбенең берсе бу-лып танылу – педагогик коллективы-бызның укучылар, әти-әниләр белән тыгыз хезмәттәшлеге нәтиҗәсе ул. Укучыларыбызда белем алуга ихтыяҗның көчле булуы, тәҗрибәле укытучыларның үз фәннәренә кызыксыну уята алуы әлеге уңышка ирешүгә ярдәм итте дә. Нәтиҗәдә узган уку елында мәктәп тәмамлаган 15 укучыбыз да бүгенге көндә югары уку йортларында белем ала, шуларның алтысы педагогик юнәлешне сайлады.

Димәк, авыл мәктәбе шартларын-да, бар предметларны татарча укытып та, БДИ буенча югары күрсәткечләргә ирешергә мөмкин икән. Безнең күрсәткечләр – моңа ачык дәлил. Әйтик, узган ел рус теленнән БДИ тапшырган укучыларыбыздан дүртесе – 80 нән, бер укучыбыз 90 нан артык балл җыйды. Математикадан ике укучыбыз 82 шәр балл җыюга иреште. Физика, биология, гео-







графия кебек предметлардан да укучыларыбызның белеме 80 нән югарырак балл белән бәяләнде. Татар мәктәбендә укыган балалар өчен бу күрсәткечләр аларның, чыннан да, төпле белемле, максатчан ул-кызлар булып үсүләрен күрсәтә. Ничек ирештекме?

Әзерлекне XI сыйныфка җиткәч кенә түгел, ә VIII – IX сыйныфлардан ук башлыйбыз. Укучыларыбыз югары уку йортларына кергәндә кирәк буласы фәннәрне ачыклауга, аларны БДИ га ныклап әзерләндерә башлыйбыз. Дәресләрдән соң көн дә консультацияләр үткәрәбез. Укучылар белән өстәмә шөгыльләнү сәгатьләре ике максатны күздә тотып оештырыла: берсе – уртача үзләштерүчеләрнең белемнәрен тагын да арттыру, икенчесе – сәләтле укучыларның БДИда югары балл алуларына ирешү. Каникул вакытларында да чыгарылыш сыйныф укучылары, көн саен мәктәпкә килеп, имтиханнарга әзерләнә, укытучылары белән индивидуаль шөгыльләнә. Ай саен мәктәбебездә сынау имтиханнары, БДИ форматындагы административ-контроль эшләр үткәрелә. Шулардан чыгып, һәр укучының нәтиҗәләре яктыртылган мониторинг эшләнә, аңлап бетермәгән темалары ачыклана, шуның буенча системалы эш алып барыла.

Район күләмендә дә сынап карау имтиханнары даими үткәрелә, мәгариф бүлеге методистлары тарафыннан, һәр баланың эше анализланып, укытучыларга методик ярдәм күрсәтелә: педагогик укулар, семинарлар, «Ачык ишекләр» көне уздырыла.

### Укытучысы нинди – укучысы шундый

Сер түгел: һәр мәктәпнең уңышка ирешүендә күп нәрсә укытучылардан тора. Укытучылар һәрдаим үз белемнәрен күтәреп, яңалыкка омтылып, заман таләпләренә җавап бирердәй дәресләр үткәрәләр. Коллективның 80 процентка якыны – үзебезнең мәктәпне тәмамлаучылар. Күбесенең эш стажы 20

елдан артык. Араларында «Россия Федерациясенең гомуми белем бирү өлкәсендәге мактаулы хезмәткәре» һәм Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» дигән күкрәк билгеләренә ия булган мөгаллимнәребез дә бар. Информатика һәм физика укытучысы Рәдиф Рәхимов, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Галина Харисова, математика укытучысы Рәзилә Гыйльманова, татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гүзәлия Мөхәммәтханова, башлангыч сыйныфлар укытучысы Гөлнара Дәүләтова, химия-биология укытучысы Сәкинә Мөхәммәтгалиева «Безнең иң яхшы укытучы» грантына лаек булганнары бар иде инде. Узган ел исә Р.Рәхимов белән Г.Харисова – «Укытучы-остаз», ә физик тәрбия укытучысы Азат Солтанов «Укытучы-мастер» грантларына ия булдылар.

### Биеклекне саклап калу җиңел түгел

Ел саен зурлап «Туган тел» көне, татар теле һәм әдәбияты атналыгы, юбиляр язучыларның иҗатына багышланган кичәләр үткәрелә. «Серле каләм», «Илһам» бәйгеләрендә катнашып, җиңүләр яулаганыбыз бар.

Балалар тәрбияләүдә гаиләләр белән тыгыз элемтәдә торабыз. Составына укытучылар, әти-әниләр, укучылар кергән мәктәп советы, профилактика советы, ата-аналар комитеты, «Әтиләр советы» эшләп килә. Ата-аналар һәм укучылар белән бергәләп төрле юнәлештәге эшләр хәл ителә. Төрле спорт ярыш-бәйгеләрен әти-әниләр катнашында үткәрүне күркәм гадәткә керттек.

Мәктәбебездә туган якны өйрәнү музее эшли. Анда укучыларыбыз җыйган 200 дән артык экспонат тупланган. Музеебыз «Авыл өе», «Дәһшәтле сугыш еллары», «Онытылмас мәктәп еллары», «Тормыш-көнкүреш җиһазлары», «Борынгы акчалар», «Кулъязма китаплар» дигән бүлекләрдән тора. Музей материаллары укучыларга, укытучыларга укыту-тәрбия процессында зур ярдәмлек булып тора. Туган якны өйрәнү эше тукталмый, укучылар, җирле материалларга нигезләнеп, төрле эзләнү эшләре белән фәнни-гамәли конференцияләрдә чыгыш ясыйлар, призлы урыннар алалар.

> Авыл мәктәбе шартларында, бар предметларны татарча укытып та, БДИ буенча югары күрсәткечләргә ирешергә мөмкин. Безнең күрсәткечләр – моңа ачык дәлил.

Мәктәбебезгә 2010 елда Татарстанның һәм Россиянең атказанган укытучысы Шамил Зиннуров исеме бирелгән иде. Шамил Зиннур улы – республикабыз халкына бик тә мәгълүм могтәбәр мөгаллим: 1965 – 1969 елларда безнең мәктәптә укыган, ә 1989 – 2010 елларда Саба районы мәгариф бүлеген җитәкләгән шәхес.

Мәктәбебездә 2010 елның 1 нче сентябреннән Ш.Зиннуров истәлегенә ачылган музей-бүлмә эшләп килә. Анда 200 дән артык экспонат тупланды инде. Материаллар җыюда Шамил Зиннур улының гаиләсе, аның бергә укыган дуслары, хезмәттәшләре ярдәм итте. Музейның «Почет китабы»н булдырдык. Анда бирегә килгән кешеләрнең истәлекләре туплана. Музей-бүлмәдә Ш.З.Зиннуровның тормыш юлы чагылган стендлар урын алган.

Мәктәбебезне тәмамлаган шәхесләр арасында биология фәннәре докторы Хатыйп Габделбарый улы Мөхәммәтгалиев, педагогика фәннәре кандидаты Рамил Хәмит улы Мирзаһитов, Татарстанның атказанган зоотехнигы, биология фәннәре кандидаты Нәҗип Нәкыйп улы Хаҗипов, Татарстанның атказанган артисты Әлфия Якуп кызы Хәсәнова, икътисад фәннәре кандидаты Фәнил Исхак улы Габдрахманов та бар. Алар – мәктәбебез горурлыгы.